| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» 2010 елның 9 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 16 сентябрендәге ПУ-616 номерлы, 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-897 номерлы, 2011 елның 25 июлендәге ПУ-432 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-187 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-458 номерлы, 2013 елның 6 августындагы ПУ-716 номерлы, 2013 елның 4 ноябрендәге ПУ-1073 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2014 елның 20 февралендәге ПУ-183 номерлы, 2015 елның 8 апрелендәге ПУ-378 номерлы, 2016 елның 31 мартындагы ПУ-323 номерлы, 2016 елның 11 июнендәге ПУ-527 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге ПУ-904 номерлы, 2016 елның 3 декабрендәге ПУ-1062 номерлы, 2017 елның 14 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2017 елның 9 февралендәге ПУ-112 номерлы, 2017 елның 5 апрелендәге ПУ-288 номерлы, 2017 елның 6 маендагы ПУ-366 номерлы, 2017 елның 10 июнендәге ПУ-496 номерлы, 2017 елның 19 июлендәге ПУ-628 номерлы, 2018 елның 25 апрелендәге ПУ-334 номерлы, 2018 елның 6 июнендәге ПУ-407 номерлы, 2018 елның 24 августындагы ПУ-583 номерлы, 2018 елның 1 ноябрендәге ПУ-762 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 21 маендагы ПУ-285 номерлы, 2019 елның 18 октябрендәге ПУ-632 номерлы, 2019 елның 5 ноябрендәге ПУ-668 номерлы, 2020 елның 4 июлендәге ПУ-383 номерлы, 2020 елның 11 августындагы ПУ-471 номерлы, 2020 елның 28 октябрендәге ПУ-714 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге ПУ-154 номерлы, 2021 елның 20 декабрендәге ПУ-973 номерлы, 2022 елның 16 мартындагы ПУ-205 номерлы, 2022 елның 22 октябрендәге ПУ-767 номерлы, 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 13 мартындагы 150 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.В. Мищихинны чыгарырга;

б) Комиссия составына Кузнецов Артем Александровичны – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы полиция башлыгы урынбасарын кертергә (килешү буенча).

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-908 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 апрелендәге ПУ-247 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 2 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-59 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-479 номерлы, 2019 елның 25 ноябрендәге ПУ-707 номерлы, 2021 елның 14 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 16 маендагы 302 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советы составына Заһретдинов Адел Линар улын – «Мәнфәгатьләрен үз вәкилләре аша белдерү ихтыяҗы, ментал ь тайпылышлары һәм башка төрле авырулары булган инвалид балаларның һәм 18 яшьтән өлкәнрәк инвалидларның ата-аналары бөтенроссия оешмасы» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсе идарәсе рәисен кертергә (килешү буенча).

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында һәркем алырлык аренда торагы базарын үстерү чаралары турында» 2013 елның 30 сентябрендәге ПУ-965 номерлы Указының 1 пункты беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды» сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ГОМУМИ БҮЛЕК · ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 25 август
№ 589